КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 август г.Казань № 1040

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче; 2016 ел, 15 февраль, 73 нче; 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче; 2019 ел, 29 июль, 629 нчы; 2020 ел, 25 август, 737 нче; 2021 ел, 19 апрель, 257 нче; 2021 ел, 8 декабрь, 1197 нче; 2022 ел, 8 июнь, 540 нчы; 2022 ел, 16 август, 843 нче, 2023 ел, 17 март, 261 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге

күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга, «алга таба - башкарма органнар» сүзләрен «алга таба - җаваплы органнар» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктта «башкарма органнар» сүзләрен «җаваплы органнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктның беренче абзацында «башкарма органнар» сүзләрен «җаваплы органнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктта «Башкарма органнары» сүзләрен «Җаваплы органнар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада:

3 графаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республика башкарма хакимият органнары һәм күрсәткеч өчен җаваплы дәүләт органнары»;

түбәндәге эчтәлекле 33 пункт өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «33. | Ихтыярыйлыкка ярдәм итүнең муниципаль программасын үтәү, процент | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | ел саен | $V = 0{,}5 \times \left(\frac{K_1 + \ldots + K_c}{c}\right) + 0{,}3 \times \left(\frac{L_1 + \ldots + L_z}{z}\right) + 0{,}2 \times \left(\frac{H_1 + \ldots + H_m}{m}\right)$,<br>монда:<br>$K_1$ - программа максатларын үтәүне характерлаучы беренче күрсәткечнең фактик мәгънәсе;<br>$K_c$ - программа максатларын үтәүне характерлый торган с күрсәткечнең фактик мәгънәсе;<br>c - программа максатларын характерлаучы индикаторлар саны;<br>$L_1$ - программа бурычларын үтәүне характерлаучы беренче күрсәткечнең фактик мәгънәсе;<br>$L_z$ - программа бурычларын үтәүне характерлаучы z күрсәткечнең фактик мәгънәсе;<br>z - программа бурычларын характерлаучы индикаторлар саны;<br>$H_1$ - программа чараларын үтәүне характерлаучы беренче күрсәткечнең фактик мәгънәсе;<br>$H_m$ - программа чараларын үтәүне характерлаучы m күрсәткечнең фактик мәгънәсе;<br>m - программа чараларын характерлаучы индикаторлар саны.<br>Муниципаль программаның максатларын, бурычларын һәм чараларын үтәүне характерлаучы күрсәткечнең фактагы мәгънәсе ирешелгән дип санала һәм, әгәр пландагы мәгънәсеннән 90 проценты һәм аннан да күбрәге ирешелгән булса, ул 100 процентка тигез дип кабул ителә». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин